УДК 398

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# «ТҮЛӘК» ДАСТАНЫНА СИСТЕМАЛЫ-КОНЦЕПТУАЛЬ АНАЛИЗ

В настоящей статье углубляется и расширяется научное изучение и анализ эпического наследия о Туляке в системно-концептуальном контексте. Автор дает описательную характеристику текстам дастана; выявляет, что на сегодняшний день найдены всего шесть вариантов татарского «Туляка»; проясняет роль религиозных воззрений народа в текстах дастана. В статье автор также определяет своеобразие дастана «Туляк» и обсуждает проблему роли эпического наследия татар в современном мире, отмечает живучесть сюжета и эпических традиций в народном творчестве в таком жанре, как «дастан җыры» («эпическая песня»), свои наблюдения аргументирует примерами из экспедиционных материалов, найденных во время научных экспедиций, организованных ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

**Ключевые слова:** дастан о Туляке; варианты, экспедиционные материалы, влияние ислама, дастанная песня, татарское эпическое наследие

This article deepens and expands the scientific study and analysis of the epic heritage of Tulyak in a systemic and conceptual context. The author gives a description of the texts of dastan; reveals that to date only six variants of the Tatar «Tulyak» have been found; clarifies the role of the religious views of the people in the texts of dastan. In the article, the author also defines the originality of the dastan «Tulyak» and discusses the problem of the role of the epic heritage of the Tatars in the modern world, notes the vitality of the plot and epic traditions in folk art in such a genre as «An epic song», argues his observations with examples from expedition materials found during scientific expeditions, organized by the G. Ibragimov Institute of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan.

**Keywords:** dastan about Tulyak; variants, expedition materials, influence of Islam, dastan song, Tatar epic heritage

Түләк һәм Сусылу турындагы архаик-героик дастан төрки халыкларның дөньяга карашларын тирән чагылдыра, шул ук вакытта татар халык иҗатының шигъри әһәмиятен дә саклый. Татар «Түләге» – кулъязмаларда килеп җиткән чын мәгънәсендә милли эпос. Әлеге сюжетка корылган дастаннарның татар вариантларына лаконизм хас, алар каһарманлык, маҗаралылыкны үз эченә ала. «Түләк» тарихи хәтерне, буыннар дәвамчанлыгын бүгенге көнгә кадәр җиткерә алуы белән актуаль.

«Түләк» дастаны («Түләк китабы» яки «Түләк белән Сусылу») фәнни дөньяга күптәннән билгеле. Бу сюжет XIX гасырда ук рус галимнәренең игътибарын җәлеп итә. В.И. Даль [5: 97–119], Л.С. Суходольский [17: 65–72], Р.Г. Игнатьев [8: 207–211], Г.Н. Потанин [16: 38–69] һ. б. ның әлеге эпик истәлеккә турыдан-туры катнашы булган

хезмәтләре билгеле. XX гасыр башында дастанның бер вариантын рус матбугатында Солтангәрәй Солтанов бастыра, 1910 елда мәшһүр шагыйрь Мәҗит Гафури (Габделмәҗит Гафуров) әсәрне аерым китап итеп әзерли һәм бастырып чыгара [7]. Соңгы елларда М. Гафури вариантының иске татар кулъязма китапларыннан төзелгән җыелма текст булуы ачыкланды [25: 4–5]. Татар эпосында «Түләк» сюжетына мөрәҗәгать итү XX гасырның икенче яртысында да дәвам итә. Мәсәлән, язучы һәм галим Н. Исәнбәт, «Түләк» операсы өчен либретто язып, бу әсәргә яңа яшәеш бирде [9]. Н. Исәнбәтнең «Түләк» пьесасы аның өч томлы «Сайланма әсәрләр» басмасының беренче томында басылып чыга [20]. Дастанның Түләк турындагы татарча версиясе алман теленә тәрҗемә ителеп, 1971 елда дөнья күргән [32]. «Түләк» дастаны безнең көннәрдә шулай ук рус теленә дә тәрҗемә ителде һәм басылып чыкты [19: 170–185].

Фольклористикада Түләк турындагы дастанның татар вариантларына багышланган хезмәтләрдән Ф. Урманчеев [29; 28: 72–89], М. Әхмәтҗанов [1; 2], М. Госманов [4: 225–300], Р. Мәрданов [25], Д. Исхаков [10: 36–71], И. Закирова [6: 75–98], Л. Мөхәммәтҗанова [12; 15: 68–76; 13] һ. б. мәкаләләре иң төп хезмәтләрдән санала. Бу темага А. Фәхретдинова тарафыннан кандидатлык диссертациясе якланган, шул ук авторның монографиясе дә дөнья күргән [30]. Фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр булуга карамастан, дастанны тулы күләмдә тиешенчә өйрәнүгә ихтыяҗ бүгенгәчә кимемәде, киресенчә, дастан белән кызыксынучылар арта, төрле аспектта яңа тикшеренүләр үткәрү зарурлыгы туа. Яңа табылган экспедиция материаллары исә дастанның татарча версиясен фәнни яктан өйрәнүнең потенциалы гаять зур булуны дәлилли.

Әсәр шактый борынгы сюжетка нигезләнгән. Барлыкка килү чоры күзлегеннән караганда, «Түләк» эпосы XIII–XV гасырларга карый [25: 6]. Дастан кыпчак кабиләләре һәм аларның варислары – татарлар, башкортлар арасында формалашкан. Дастанның мифологик үзенчәлекләреннән күренгәнчә, аның архаик тамырлары борынгы төркиләр фольклорына барып тоташа. Түләк исеме белән бәйле әсәрләр бүгенге көнгә татар һәм башкортлар яшәгән төбәкләрдә билгеле. М. Госманов сүзләренчә, «бер эпосның ике халык иҗади репертуарында да булу факты бик аңлаешлы: татарлар белән башкортлар, борынгы заманнардан ук бергә аралашып, һаман янәшә яшәгәннәр. Гасырлар буена сузылган менә шушы янәшәлек, күршелек, хәтта гел яңарып торган кардәшлек нәтиҗәсендә фольклорда андый уртак сюжетлар барлыкка килүе әллә ни гаҗәп түгел» [4: 235].

Башкорт халкында дастан яки дастаннан өзекләр телдән башкару характерында булса [31: 14], татарларда, телдән вариантлар белән беррәттән, дастанның язма-китаби вариантлары зур популярлык казанган, чөнки татарларда дастан – язма мәдәният тәэсирен кичергән эпик жанр. Китап культурасын үстерүгә зур йогынты ясаган булулары, язма әдәби-мәдәни процессны югары баскычка күтәрүдә әһәми-

ятле функция үтәүләре – башка халыклар белән чагыштырганда татар эпос-дастаннарының төп үзенчәлеге. Халкыбыз күләмле дастаннарны берничә гасыр элек кәгазьгә төшергән, ягъни мәгълүм дастани сюжетлы иң камил, иң төзек вариантлар язмага теркәлеп, кульязма нөсхәләр яисә китапка әверелеп таралган [14: 15–125]. Бу закончалык «Туләк» дастанының татар версиясенә дә хас. Татар телендәге язма-китаби «Туләк» дастаны текстлары, гарәп язулы кульязмалар булып, хәзерге көннәргә килеп җиткәннәр. Галим Д. Исхаков сүзләре белән әйтсәк, дастанның «...иң борынгы һәм тулы версиясе язма рәвештә (кульязмасы XVI йөзгә карый) татарларда гына сакланган» [10: 37]. Шул ук вакытта «Туләк» дастаны вариантларына күзәтү ясау татарларның китаби характердагы «Туләк» дастаны да төрки сөйләмә дастаннар традициясен дәвам итеп үсеш алган, дигән фикерне куәтли.

Дастанның эчтәлегенә кыскача тукталыйк. Татар телендәге Туләк турындагы версиядә әйтелгәнчә, Туләкнең иптәшләре аны гел рәнҗетәләр, ау кошларыннан аңа фәкать кечкенә генә ябалак, атлардан исә ике яшьлек юбалгы тай эләгә. Ә иптәшләре үзләренә яхшы аргамаклар сайлыйлар. Эпос традицияләре һәм кануннары буенча, торабара Туләкнең йолкыш тае җилне узып чабарга сәләтле чын атка, ә ябалак-кошы лачын-кошка әверелә. Туләкнең бу кадәр уңышка ирешүе, төшеп калмыйча, проблемаларын уңышлы хәл итүе, әлбәттә, аның иптәшләрендә көнчелек уята. Алар, сүз куешып, Туләк Аргамагының тоякларына кадаклар кагып куялар. Вакыйгалар Балкантауга якын урында бара. Күп сынаулар кичергән дастанның төп каһарманы Туләк болардан аерылып, читкә китә. Бу – төркиләрнең героик дастаннарында еш кабатлана торган мотив – каһарманның төрле сәбәп белән туган җиреннән читкә чыгып китү мотивының «Туләк» дастанында чагылышы. Кайбер вариантта Туләк йөз иптәшеннән китә диелә, кайберсендә кырык егеттән яки явыз күршеләрдән качуы бәян ителә. Туләкнең үсмер вакыты батыр балачак буларак тасвирлану – шулай ук төрки героик дастаннарның барысына да хас сыйфат. Батыр балачак мотивы булган бу өлеш «Туләк»нең кайбер вариантларында сакланмаган, әсәр шунда ук икенче өлештән башлана, әмма бу вакыйгаларның булганлыгы әсәрнең икенче өлешенең логик эчтәлегеннән һәм эзлеклелегеннән аңлашылып тора.

Алга таба Туләк юлга кузгала. Туләк образы һәм аның гамәлләре аша бу өлештә сюжет тагын да үстерелә. Батыр юлын дәвам итә һәм яңа сынаулар аша уза. Дастанның күпчелек вариантларында Туләкнең Сусылу белән очрашуы турында сөйләнелә. Сусылу – татар халык авыз иҗатында Су анасы образына бәйле мифологик персонаж. Аның дастан сюжетына килеп керүе төрки халыкларда борынгы су культына барып тоташа.

Бик борынгы мифологик карашлар буенча, Җиһанны чолгап алган тирәлек бары тик судан гына торган. Суның хуҗасы – Су иясе бар дип саналган, аның исеме Су анасы яки Су бабасы [27: 58–74]. Су анасы – җирдән тыш читтәге дөнья – су мохите вәкиле. Су көченә

ышанулар татарларда бүгенге көндә дә очрый. Мәсәлән, суга батучы турында *«Су анасы алган»* дип әйтү сакланып калган. Бу – татарларның су асты патшалыгы турында исламга кадәрге борынгы фикерләүгә бәйле мифологик күзаллауларыннан ук килә. Суда яшәүче Су анасы безнең көннәрдә шартлы рәвештә түбән мифология персонажларыннан берсе санала. Кешенең табигать белән тәңгәллеген һәм охшашлыгын аңларга омтылу «Түләк» дастанында герой язмышын Сусылу мифологик атрибуты белән бәйли. Су стихиясе вәкиле Сусылу белән җир кешесе Түләк арасында сөйләшү башлана:

*Андан Түләк әйтде:*
*– ...Суның кызы Сусылу,*
*Сәнең берлән булаем,*
*Атың әйтче, Сусылу!*
*Андан кыз әйтде:*
*– Хуш хәмаил, хуш йөзек*
*Алмадың син, Түләгем!*
*Алтын сыргам, ал йөзек –*
*Янә бирдем – бүләгем.*
*Бүләк биреп алмыйсән,*
*Нидер сәнең теләгең?*
*Сүзең әйтче, Түләгем?*
*Андан Түләк әйтде:*
*– Хуш хәмаил, хуш йөзек –*
*Зифа йөзең бизәгел!*
*Алтын тарак, ал көзгене*
*Мән ни итим, Сусылу?*
*Йөзек-бүләк кирәкмәс,*
*Зифа буең – теләгем!*
*Сүзем шулдыр, Сусылу!* [18: 126–127]

Кыз Түләкнең үгет-нәсыйхәтенә һич бирешми, ул Сусылуны үзенеке итә алмый. Герой белән озын чәчле су чибәре арасындагы сүз диалогы акрынлап физик көрәш формасын ала, Сусылу үз мохитенә, су астына китәргә тели. Ә Түләкнең аны җибәрәсе килми. Билгеле бер мизгелдә аны ычкындырачагын күреп, Түләк Сусылуны су өстендәге чәчләреннән эләктереп ала да, кызны судан тартып чыгарырга тырышып, толымнарын кулына чорный башлый.

Мифологик ышанулар буенча, су хуҗасы, ягъни Су иясе һәм аның нәселе – Су бабасы (Су атасы), Су анасы, Су кызы һ. б. су астында яшиләр һәм үз патшалыкларында хуҗалык алып баралар [11: 162]. Төрки мифологиядә киң таралган су культы архаик-героик дастанның татар версиясе сюжетында сәнгати-фантастик яктан ачыла. Су асты чибәре белән көрәштә бу дөнья кешесе Түләк җиңелүгә дучар була, ул Сусылу белән бергә су асты патшалыгына эләгә, су стихиясенең хуҗасы – Сусылуның этисе каршына баса. Чачдархан Түләккә кызы Сусылуны никахлап бирә. Түләк берникадәр вакыт Сусылу белән бәхетле яши. Су иясе тормышын һәм хуҗалыгын гәүдәләндереп,

«Түләк» дастаны татарларның борынгы карашларын бүгенге көнгә кадәр җиткерә. Алга таба сюжет буенча Түләк туган җирен сагына башлый, үз иленнән башка яши алмавын аңлый. Чачдарханның аңа туган җиренең Балкантавын диңгез төбенә күчерергә тырышуы да юаныч китерми. Түләк кире үз җиренә кайта.

Бүген татар телендәге «Түләк»нең алты варианты билгеле. Текстлар бер-берсеннән, нигездә, тәрҗемә итү вакыты һәм урыны, тулылыгы яки тулы булмавы, текстта архаик лексика кулланылышы дәрәҗәсе, шигъри өлешләрнең кайбер үзенчәлекләре һ. б. белән аерыла. «Түләк» дастанының һәр татар варианты бер үк дәрәҗәдә кыйммәткә һәм зур фәнни әһәмияткә ия.

«XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия» җыентыгында басылган вариантка [33: 267–284] тукталып үтик. Татар язма дастаннары арасында бу кульязма үзенең күләме белән аерылып тора. Ул 1991 елда Казан шәһәрендә инженер, язучы Зөфәр Кормашев архивында галим-текстолог М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табылган, дастан тексты аның тарафыннан ук басып чыгаруга әзерләнгән. Табылдыкны 1985 елда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгенә мәрхүм Зөфәр Кормашевның хатыны – Мөнирә Җәләлетдин кызы Кормашева тапшырган. Дастанның шартлы атамасы – «Түләк»нең Казан варианты. Кәгазьгә 1887 елда күчерелгән. Күчереп язучы – Мөхәммәтгәрәй бине мелла Шакирҗан, Минзәлә районының Теләнче Тамак авылындагы Габделҗаббар хәзрәт мәдрәсәсе шәкерте. Текст 162 биттән торган кульязмада теркәлгән [23]. «Түләк китабы» дастанының Казан вариантына багышланган берничә фәнни мәкалә басылып чыккан [1; 2].

«Түләк» дастаны татарча версиясенең бу үзенчәлекле вариантында төп геройның мавыктыргыч тарихларына басым ясала. Чыганакта Идел-Кама һәм Урал буе территорияләренә хас географик атамалар, Алтын Урда чорында бу тирәләрдә халыкның табигатькә чыгып күңел ачуына, корбан чалуларына һ. б.га бәйле күчмә тормыш рәвеше телгә алына. Тикшеренүчеләр раславынча, дастанда сүз бара торган Балкан тавы (Балкантау) хәзерге Башкортстан Республикасының Дәүләкән районындагы «Асылы күл» дигән күлгә якын гына урнашкан шул ук исемдәге тау белән тәңгәл [10: 45–47].

Дастанда ислам йогынтысы көчле, биредә ул маҗаралы характер алган. Текстта Коръән персонажлары да бар, шулай ук мөселман йолалары һәм гореф-гадәтләре тасвирлана. Текст башында сюжетта Коръән каһарманы – Хозырның булуына игътибар итәбез. Хозыр төшендә Түләккә килә һәм аңа Аллаһның 99 гүзәл исеме санап үтелә торган «Исме Әгъзам» догасын өйрәтә. Үз проблемаларын хәл итү һәм дошманнарының мәкереннән котылу өчен, Түләк Аллаһка корбан итеп тәкә китерергә, картларны корбан ите белән сыйларга, шулай ук дога укырга тиеш була. Түләк барысын да төгәллек белән башкара. Аллаһы Тәгаләгә өмет баглау каһарманга уңыш китерә. Алга таба кискен моментларда Түләк үз эшләрендә һәрвакыт әлеге сыналган

ысулны куллана. Мәсәлән, Чачдар ханның игътибарын үзенә җәлеп итәр өчен, иртәнге намаздан соң ул ике рәкәгать өстәмә намаз, «Исме Әгъзам» укый һәм Аллаһтан бу илгә түзә алмаслык эсселек иңдерүен сорый. Кызудан интеккән Чачдар Түләк янына тәүбә итеп килсен һәм бәладән котылу өчен кызы Сусылуны үзенә бирсен өчен шулай эшли. Түләк теләгәненә ирешкәч, Аллаһтан сорап, барысын яңадан үз урынына кайтарта:

*«Түләк чыкты, кешесез урында таяммум итте, ихластан ике рәкәгать хаҗәт намазын укыды. "Исме Әгъзам" догасын укыды, баш иеп, сыгынып Аллаһка: "Я Раббым, минем авырлыкларымны син җиңел итә аласың, рәхим-шәфкатеңне күрсәт, хәлдән тайдырган эсселекне бу халыктан ал, рәхим-шәфкатеңне иңдер!" Ихласлыгы белән ялварып сорады, шул вакыт салкынча җил исеп, бал елгасы, сөт елгасы, су елгасы акты»* [23: 7].

Бөтен шартын төгәл үтәп, су белән тәһарәтләнү урынына таяммум гына үтәү урта климат шартларында яшәүчеләргә караганда сусыз коры чүлдә яшәүчеләргә күбрәк хас. Әлеге элементның татар вариантында булуы сюжетның бер өлеше яки билгеле бер детальләрнең дастанга Көнчыгыш язма истәлекләреннән күчкән булу мөмкинлегенә ишарә итә. Шәрык дастаннарыннан яхшы билгеле кайбер сюжетлар, мәсәлән, чүлгә чыгу (чүлгә китү), табигатьтә ял итү (сәхрәгә чыгу) кебек, татарларның башка китаби дастаннарында да киң таралган булган, алар, мәсәлән, сюжеты Борынгы Көнчыгыш язма истәлекләреннән алынган «Ләйлә – Мәҗнүн», «Таһир һәм Зөһрә»нең күп вариантларында әллә ничә кат кабатлана [14: 258, 318, 319]. Әмма шул ук вакытта бу элементның татар вариантында ислам традицияләре һәм Коръән тәэсире астында барлыкка килү мөмкинлеген дә кире какмыйбыз.

Таяммум йоласы дастан текстында Чачдарханның су асты патшалыгында урнашкан түзә алмаслык эсселек белән бәйле рәвештә тасвирлана. Барлык елгалар һәм су чыганаклары кипкәч, биш вакыт намаз алдыннан су белән гадәти тәһарәтләнү мөмкинлеге калмый. Дастанны күчереп язучы, мөселман буларак, таяммумны башкару тәртибен, аны нинди очракларда башкарырга кирәклеген яхшы белә һәм бу элементны дастан сюжетында мөстәкыйль дә куллана алган.

Бу вариантта Түләк мөселман буларак сурәтләнгән, ул намазын калдырмый, ә соңрак хатыны Сусылу да аңа иярә, мөселманга тиеш төп шартларны үти башлый. Дастанда Түләкнең Аллаһка мөрәҗәгать итеп теләгән теләкләре шунда ук тормышка аша бара. Аллаһ Түләкнең гыйбадәт артыннан сораган һәр үтенечен кичекмәстән үти. Сюжетта доганың шул арада кабул булуын күрсәтә торган акцент куелуда, мөгаен, төрки эпик традицияләр белән яхшы таныш булган, табигать көчләренең кичекмәстән кешегә ярдәмгә килүенә һичшиксез ышанган күчереп язучының менталитеты зур роль уйнагандыр. Дастанда эпик геройны олылау, аңа яхшырак шартлар тудырырга омтылыш, каһарманны көчле, зуррак мөмкинлекләргә ия итеп

күрсәтү, аны башкалардан аерып кую, мактау, эпос кагыйдәләренә гомумән хас булганча, эпик каһарманны калку сурәтләү традициясеннән дә килергә мөмкин. Архаик-героик, тарихи-героик, соңрак дини-героик татар дастаннарының күбесендә әлеге закончалык сакланган. «Түләк» дастаны да бу җәһәттән чыгарылма түгел.

Моннан тыш, тикшеренүчеләр фикеренчә, Түләкнең реаль чынбарлыктагы прототибы затлы нәселгә – Бөек Монгол империясенә нигез салучы кыйатларга барып тоташа [10: 42–43]. Дастанның үзендә дә Түләкнең түрә булганлыгына бик күп ишарәләр бар. Ул – һәрвакыт кыю, батыр, карарны тиз кабул итүчән, үз дигәненә ирешүчән, үз сүзен сүз итүчән курку белмәс каһарман. Су төбендә дә тәхетен сагына. Болар барысы да – Түләкнең югары социаль статуска ия булуы хакында сөйли торган сыйфатлар. Түләк шәхесенә күләмле эпик әсәр иҗат ителү үзе генә дә әлеге фикерне яклый. Урта гасыр әдәби-мәдәни традициясендә хан-солтаннарга багышлап күләмле әсәрләр иҗат итү традициясе булганлыгы билгеле. Болардан чыгып фикер йөрткәндә, Түләк исеме белән аталган әсәрдә Түләкнең өстенлекле вәкаләткә ия булуы эпик кануннар белән генә аңлатылып калмыйча, реаль җирлеккә дә дәгъва кыла.

Дастанда ислам чынбарлыгы традицион дөньяга карашлар белән катнаштырылган, ягъни дастан структурасына кешенең дөнья турындагы кайбер архаик күзаллаулары да бик җиңел кереп урнашкан. Этномәдәни катламнарның болай урнашуы файдасына дастанда төп геройларның гарәпчә түгел, ә типик төрки исемнәр белән – Түләк, Сусылу, Чачдархан һ. б. – аталуы да сөйли. Моннан чыгып, әсәрнең сюжет канвасы исламга кадәрге төркиләр арасында ук барлыкка килгән дип уйларга нигез бар.

Дастанның икенче варианты – М. Гафури тарафыннан 1910 елда төзелгән җыелма текст. Китапның татар телендәге кереш сүзендә әдип үзенең 1909 елда Бәләбәй өязенә баруы, анда «Заятүләк»нең көен җырлап уйнаулары, «Заятүләк» дигән китап та бар дип ишетүе турында яза. «Мин элек бу китапның Уфада мәшһүр бер зат тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, үзе вафат булуы сәбәпле бастырылмый калуы турында ишеткән идем. Монда да буның барлыгын ишеткәч, аны шундук эзләп таптым. Кулыма төшкән мөтәгаддид (*күпсанлы*) нөсхәләрне бергә китереп караганда, китапның әһәмияте мин уйлаганча булмаса да, түбәндәге сәбәпләр өчен язып алып, тугры килсә табигъ кылдырырмын (*нәшер итәрмен*) дип уйладым», – ди ул [7: 3]. Әсәрнең шигъри өлеше, стиле дастанның башка татар вариантлары белән охшашлыгы турында сөйли, әмма сюжетта аз гына аермалар бар. Дастанның М. Гафури варианты язучының соңрак дөнья күргән басмаларына, аннары «Башкорт халык иҗаты» җыентыгына башкорт эпосы үрнәге буларак кертелгән [3].

М. Гафури тексты Олы Кариле авылында табылган кульязмага якынрак (бу кульязма турында сүз алдарак барачак). Аларны хәтта бер кульязманың ике варианты дип тә карарга мөмкин. Бертөрле

диярлек чәчмә һәм шигъри өлешләрнең тотрыклылыгы, стиль урталыгы да шуны күрсәтә. Төп аерма – күчереп язу вакыты һәм урынының үзенчәлегендә һәм күчереп язучыларның грамоталылык дәрәҗәсендә.

«Түләк»нең тагын бер вариантының кулъязмасы (бәлки берничә вариантның җыелма кулъязмасы) Н. Исәнбәтнең шәхси архивында саклана дигән мәгълүмат та бар. Мәгълүм булганча, дастанның Түләк турындагы кулъязмасына нигезләнеп, 1929 елда Н. Исәнбәт пьеса яза башлый. Үз вакытында опера һәм балет театрының әдәбият бүлеге җитәкчесе Муса Җәлил Н. Исәнбәткә операга либретто язарга тәкъдим итә. Нәтиҗәдә, «Түләк» драматик поэмасы иҗат ителә. Н. Исәнбәт вариантында «Түләк» беренче тапкыр 1944 елда басылып чыга [9].

Кызганычка, бу текстның нинди чыганаклар нигезендә барлыкка килүе турында әлегә бик аз билгеле. Кулъязманың язылу вакыты да анык түгел, ул – Түләк турындагы дастанның тулы түгел варианты буларак характерлана: документның соңгы битләре югалган. Композитор Х. Ибраһимов Н. Исәнбәтнең «Түләк» әсәренә җырлар, арияләр яза. Композитор Н. Җиһанов шул исемдәге опера иҗат итә. Опера Бөек Ватан сугышы елларында, шулай ук 1970 елларда куела.

«Түләк» дастанының тагын бер варианты 1969 елда Кама Тамагы районы Олы Кариле авылында Казан (Идел Буе) федераль университеты тарафыннан тарихчы галим Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә оештырылган археографик экспедиция вакытында табыла. Бу кулъязманың оригиналы КФУда Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана [21]. Документ – 32 битле, язулы 64 биттән тора, шактый иске, тузган, тулы булмаган нөсхә. Дастанның ахыры теркәлгән соңгы битләр барыннан да бигрәк зыян күргән. Кулъязманың XIX гасырның икенче яртысында күчереп язылган булуы билгеле. Күчереп язучы – Олы Кариле авылыннан Хәсән исемле укымышлы. Кулъязма табылган, өйрәнелгән, хәзерге язуга күчерелгән, академик М. Госманов тарафыннан өлешчә реконструкцияләнгән. «Түләк»нең бу варианты турында тарихчы үзенең мәкаләсендә җентекләп бәян итә [4: 117–132], мәкаләгә кушымтада ул дастан текстын транскрипцияләп бастыра. «Түләк китабы» дастанының бу варианты шартлы рәвештә «Кариле варианты» дип атала.

Бишенче вариант – Татарстан Республикасы Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында табылган кулъязма. Аны фәндә Мәңгәр варианты (Олы Мәңгәр кулязмасы) дип атау кабул ителгән. Дастан 1994 елда Татарстанның Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табыла. Кулъязманы галимгә авылда яшәүче Закировлар гаиләсе тапшырган. Ул дүрт биттән тора. Текст тулы түгел, кайбер битләр югалган, текст фрагментар характерда. Дастанның бу вариантының стиле һәм теле, кулланылган кәгазе һәм карасы XVIII гасырның икенче яртысына карый. Күчерүчесе турында мәгълүмат юк.

Кулъязма Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондында саклана [22].

Алтынчы вариантны 1996 елда Самара өлкәсенең Камышлы авылында тарихчы-галим, археограф, текстолог Р. Мәрданов тапкан. Дастанның бу варианты турында тәүге мәгълүмат Р. Мәрданов төзегән китапта авторның җентекле махсус фәнни мәкаләсендә китерелә. Шунда ук дастан тексты да урын алган [25]. Дастан тексты XIX гасырның беренче яртысында күчереп язылган җыентыкта урын алган, 10 биттән тора. Текстны Спас өязенең (хәзерге Татарстан Республикасы Әлки районы) Зур Тигәнәле авылы мулласы, Казан губернасы Чистай өязе (хәзерге Татарстан Республикасы Чистай районы) Мөслим авылында туып үскән Сибгатулла бине Фәхретдин Мөдәррис (1820–1875) тарафыннан теркәлгән. Бу вариант шактый тулы, «Түләк»нең башка билгеле кулъязмалары белән уртак яклары күп. Дастанның сюжеты күп очракта алдагы вариантлар белән тәңгәл. Гарәп сүзләренең төрлечә язылуын, күчереп язучының язу рәвешен, кайбер стилистик һәм орфографик үзенчәлекләрен һ. б. текстның төп аермалы яклары дип күрсәтергә кирәк. Түләк белән Сусылу диалогларындагы лексика соңгы вариантта эмоциональрәк булуы белән аерылып тора. Р. Мәрданов үзе бу хакта җентекләп сөйли. Китап ахырында кулъязманың факсимилесы, текстның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе һәм элегрәк табылган вариантларның күчереп язу вакыты һәм урыны күрсәтелгән чагыштыру таблицасы китерелгән. Текстның төп нөсхәсе Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана [24].

«Түләк» дастанында халыкның тарихы, гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгатенең кабатланмас бизәкләре урын алган. Әлеге бәһаләп бетергесез зур мирас бүгенге көндә дә иҗтимагый тормышыбызда билгеле бер роль башкара килә. «Түләк» дастаныннан килә торган традицияләрнең онытылмавы шул хакта сөйли. Бүгенге көндә дастан каһарманының исеме, дастан вакыйгалары опера-балет, театр сәхнәләрендә һәм әдәбият мәйданында яшәвен дәвам итә. Татар фольклорындагы «эпик җыр» дип аталган, «Түләк» сюжетыннан этәрелеп, дастан авазын безнең көннәргә китереп җиткергән дастани җырларыбызның бүгенге көндә дә яңгыравы, татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә әле дә язып алына торуы да хаклы рәвештә «Түләк»нең дәвамы, татар җәмәгатьчелегендә бу жанрга карата булган ихтыяҗның чагылышы дип бәяләнә ала.

Бүген ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ тарафыннан татарлар тупланып яшәгән төрле төбәкләргә оештырылган фәнни экспедицияләр вакытында халыктан сораштырулардан күренгәнчә, «Түләк китабы» исемле әсәр халыкның тарихи хәтерендә саклана. Тарихи хәтер, милли эпик код бу очракта информантның *«Әйе, «Түләк» дип ишеткән бар. Су төбендә яшәгән Түләк. Аны элек китаптан укыганнар, иске китаптан»* (информант – Татарстанның Азнакай районы Җиңү авылында Гәрәева Сәгадәт Бари кызы (1927 елгы)),

дигән кыска гына мәгълүматына яшеренгән. Бүгенге көндә «Түләк» дастанының яңа кулъязмасына юлыгу – бик сирәк күренеш, әмма дастан кайтавазы буларак фабула характерындагы сөйләкләр, яисә дастан җыры дигән жанр атамасы белән мөстәкыйльләшеп бара торган шигъри юлларга әле бүгенге фәнни экспедицияләр вакытында да юлыгып торабыз. Бүгенге чор өчен мондый ядкәргә юлыгу – зур табыш. Мәсәлән, «Түләк» дастаны турында югарыда телгә алынган азмы-күпме мәгълүматлы информант Гәрәева Сәгадәт Бари кызы дастаннан түбәндәге дүрт юл тезмәне әйтеп бирде (2019 ел, язып алучы – Л.Х. Мөхәммәтҗанова):

*Балкан тавы монда юк,*
*Ак киегем монда юк.*
*Утырып уйлар уйларга*
*Алтын тәхетем монда юк* [26].

«Түләк» дастаныннан эпик җыр буларак мәгълүм бу юллар дастанның тулы вариантларындагы Түләк җыры белән сүзгә сүз диярлек аваздаш:

*Балкан тавы монда юк,*
*Ак киегем монда юк.*
*Ултырып уен уйнарга*
*Алтын тәхетем монда юк!*
*Җөмлә буем җофары,*
*Зифа ярым монда юк* [18: 134].

«Түләк» дастанының XXI кайтавазы дип бәяләнә торган әлеге дүртьюллык тезмә – фольклорда кире бәйләнешнең ныклыгын исбатлый торган сирәк үрнәк. Ягъни билгеле бер чорда китаби эпоска әверелгән дастан, трансформацияләнеп, бүгенге чорда яңадан телдән сөйләмдә чагылыш таба. Мондый күренешләр массачыл төс алган дип әйтә алмасак та, борынгы «Түләк» дастаны халкыбызда эзсез юкка чыкмаган, димәк, тарихи хәтер дә исән. Дастаннар һәм дастан традицияләре – буыннан буынга тапшырылып килә торган олы мирас, бу байлыкны файдалану, дастаннар сюжетында, стилендә, башкарылу үзенчәлекләрендә булган нечкәлекләрне килер буыннарга җиткерү, милли үзаңны үстерү, асылыбызны саклауны нәтиҗәлерәк итә.

Түләк турындагы дастан – татар эпик фольклорының иң архаик үрнәкләреннән берсе. Тулаем алганда, татар версиясе төрки эпос өчен классик булган шигырь һәм проза чиратлашу формасында төзелгән. «Түләк» дастанында архаик, урта гасыр, исламга кадәрге һәм мөселман чоры катламнары чагылыш тапкан. «Түләк китабы» – халык иҗаты җимеше. Дастанда тарихи чынбарлык, этносның исән калу һәм кырыс әйләнә-тирәгә җайлашу өчен көрәше, шулай ук ыруглык җәмгыяте җимерелү чорында патриархаль мөнәсәбәтләр һәм идеаллар, шулай ук соңгырак чорның социаль-мәдәни үзгәрешләре, экияти-мифологик һәм эпос-дастан эстетикасы белән тыгыз бәйләнештә чагылыш тапкан. «Түләк» эпосының кулъязма татар вари-

антлары дастанның татар халкы арасында киң таралуын, халыкның сүз-шигъри иҗатында лаеклы урын алуын күрсәтә. Дастанның Түләк турындагы тикшеренү темасы моның белән генә бетми. Аның татар вариантларын төрле аспектларда өйрәнүнең потенциалы бик югары, телдән эпик традицияләр кысаларында барлыкка килгән һәм вакыт узу белән китаби төр дастанына әверелгән әсәрләр, шулай ук эпик җыр формасында бүгенге көндә дә очрап куя торган авыз-тел ядкәрләре, бик сирәк фольклор материалы буларак, тема буенча алга таба тикшеренүләр алып баруга киң мөмкинлекләр ача.

**Әдәбият**

1. *Ахметзянов М.И.* Казанский список дастана «Туляк и Суслу» // Старотатарский литературный язык: исследования и тексты. Казань: ИЯЛИ, 1991. С. 89–97.

2. *Әхмәтҗанов М.И.* Түләк белән Сусылу. Түләк китабы // Әдәби мирас. Дүртенче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 14–33.

3. Башҡорт халыҡ ижады. Эпос. 1-се китап / төҙөүсе, баш һүҙ яҙыусы, аңлатмалар биреүсе М.М. Сәғитов. Өфө: Башҡорт кит. нәшр., 1972. 242 б.

4. *Госманов М.А.* Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Тулыл. икенче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 463 с.

5. *Даль В.И.* Башкирская русалка // Москвитянин. 1843. № 1. С. 97–119.

6. *Закирова И.Г.* Болгар чоры халык иҗаты. Казан: Фикер, 2003. 144 б.

7. Заятуляк берлә Сусылу: башкорт хикәясеннән / төз. М. Гафури. Уфа: Тип. «Товарищество Каримов, Хусаинов и К°», 1910. 24 б.

8. *Игнатьев Р.Г.* Сказания, сказки и песни, сохранившиеся в рукописях татарской письменности и в устных пересказах у инородцев-магометан Оренбургского края // Записки Оренбургского отдела императорского Русского географического общества. Вып. 3. Оренбург, 1875. С. 207–211.

9. *Исәнбәт Н.* Түләк батыр: опера өчен либретто // Совет әдәбияты. 1944. № 4. Б. 27–36; № 5. Б. 25–33.

10. *Исхаков Д.М.* Халкыбызның эпик әсәрләрендә милли тарих («Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннары һәм тарихи риваятьләргә анализ): моногр. Казан: ООО «Грумант», 2022. 160 с.

11. Мифы народов мира. Энциклопедия: в 2 т. Т. 2. К–Я / гл. ред. С.А. Токарев. М.: Советская энциклопедия, 1992. 719 с.

12. *Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Түләк китабы // Казан утлары. 2024. № 6 (1208). Б. 168–184.

13. *Мухаметзянова Л.Х.* Архаические пласты и исламские воззрения в татарской версии дастана «Туляк» // Эпосоведение. 2024. № 3. С. 5–14.

14. *Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ, 2014. 380 с.

15. *Мухаметзянова Л.Х.* Эпическая культура татар. Дастаны. Казань: ИЯЛИ, 2023. 120 с. (Серия «Обычаи и традиции татарского народа»).

16. *Потанин Г. Н.* Дочь моря в степном эпосе // Этнографическое обозрение. Кн. XII. 1892. № 1. С. 38–69.

17. *Суходольский Л.С.* Легенда о Туляке // Вестник императорского Русского географического общества. Ч. 24. № 12. СПб., 1858. С. 65–72.

18. Татар халык иҗаты. Дастаннар / томны төз., кереш мәкалә һәм иск. язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 с.

19. Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 8. Дастаны / сост. тома, авт. вступ. ст. и коммент. Ф.В. Ахметова. Казань: Татар. кн. изд-во, 2019. 471 с.

20. Түләк // Исәнбәт Н. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. Б. 310–367.

21. Түләк // Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исем. фәнни китапханәсе. Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, шифр 4474-т, 32 б.

22. Түләк // Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең Язма мирас үзәге. Колл. 39. Сакл. бер. 1. Тасв. 1. Б. 4.

23. Түләк китабы // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең Язма мирас үзәге. Колл. 39. Сакл. бер. 5011. Тасв. 1. Б. 162.

24. Түләк китабы // Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исем. фәнни китапханәсе. Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, шифр 1761т. Б. 10.

25. Түләк китабы: дастан / төз.-авт. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2008. 75 с.

26. Түләк. Дастан җыры / Информант – Гәрәева Сәгадәт Бари кызы (1927 елгы). 2019 елда Татарстанның Азнакай районына ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ оештырган комплекслы фәнни экспедициядә Җиңү авылында язып алынды // Экспедиция материаллары. Л.Х. Мөхәммәтҗанованың шәхси архивы.

27. *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 3 т. (С–Я). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 199 б.

28. *Урманчеев Ф.И.* Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 312 с.

29. *Урманчеев Ф.И.* Татарско-башкирские сказания о Туляке // Советская тюркология. 1979. № 6. С. 10–25.

30. *Фахрутдинова А.Р.* Дастан «Туляк и Сусылу»: тюрко-татарские варианты. Казань, 2011. 124 с.

31. *Юлдыбаева Г.В.* Башкирский народный эпос «Заятуляк и Хыухылу» (история собирания, издания и исследования) // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2015. № 8 (50): в 3-х ч. Ч. III. С. 214–217.

32. *Csikai V.* Eine unveröffentliche baschische Volksmärchen-variante // Acta orientalia. 1971. T. XXVIII. C. 55–77.

33. XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия / төз. М. Әхмәтҗанов. Казан: Матбугат йорты, 2006. 363 б.

**Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,**
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

**Мухаметзянова Лилия Хатиповна,**
*доктор филологических наук, доцент, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*lilmuhat@mail.ru*